ВЕСЬ ТАТАРСТАН
БӨТЕН ТАТАРСТАН

# МИНЕМ КАЗАНЫМ

ЮЛКҮРСӘТКЕЧЕ







# МИНЕМ КАЗАНЫМ

## ЮЛКҮРСӘТКЕЧЕ

ТАТАР БАЛАЛАР НӘШРИЯТЫ
ТАТАРСКОЕ ДЕТСКОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО



# КАЗАНЫМ

**Сәлам!**
**Минем исемем – Зилантик.**

Мин Казанда яшим. Бу шәһәр – Татарстан Республикасы башкаласы. Монда төрле милләт вәкилләре яши.





Алар шәһәргә үз мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен бүләк иткән. Шуңа күрә Казан үзенең кунакчыллыгы белән дан тота.

Мин Казан шәһәренең тарихын беләм һәм аның барлык истәлекле урыннары белән таныш. Әйдә, мин сиңа барысын да күрсәтәм!



# Казан Кремле

Казанга 1000 елдан артык икәнен син беләсеңме? Казан Кремле – шәһәрнең үзәге. Аның ак диварлары артында Татарстан Президенты резиденциясе, Сөембикә манарасы, Благовещение соборы, Кол Шәриф мәчете, берничә музей һәм башка истәлекле урыннар бар. Казан Кремленә ел саен дөньяның төрле почмакларыннан меңәрләгән турист килә.



# Казан Кремле


Казан Кремле ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы Исемлегенә кертелгән. Ул әлеге оешма сагы астына алынган. ЮНЕСКО, тарихи һәйкәл җимерелмәсен һәм җир йөзеннән юкка чыкмасын өчен, аны игътибар белән күзәтеп тора.



# Благовещение соборы

Благовещение соборы – тагын бер гаҗәеп матур тарихи һәйкәл. Бу – Казан Кремлендәге иң борынгы корылма.

Собор псков-новгород төзелеш сәнгате мәктәбе традицияләрендә салынган. Чиркәү берничә мәртәбә янса да, һәрвакыт яңадан төзекләндерелгән.



# Сөембикә манарасы

Сөембикә манарасы – борынгы Казан символларының берсе. Казанның иң серле риваятьләренең берсе әлеге корылма белән бәйле.

Риваять буенча, манараны Явыз Иван җиде көн эчендә төзеткән (көн саен бер каты салынган). Бу рус патшасының Казан ханлыгы ханбикәсенә бүләге була.



# Кол Шәриф мәчете

Кол Шәриф – Татарстанның иң гүзәл һәм атаклы мәчетләренең берсе. Ул 2005 елда төзелә.

Мәчет татар халкының күренекле мәгърифәтчесе һәм имамы Кол Шәриф исемен йөртә.

Мәчеттә Ислам музее урнашкан.



# Кол Шәриф мәчете



# Губернатор сарае

Бу корылма Казан Кремленең төньяк өлешендә урнашкан. Элек нәкъ бу урында Казан ханы сарае булган.




# Губернатор сарае

Хәзерге вакытта Губернатор сараенда Татарстан Республикасы Президенты резиденциясе урнашкан.



# Ратуша

Европа калаларының үзәк мәйданында шәһәр гербы һәм сәгате белән бизәлгән төп бина – ратуша урнашкан. Казанның да үз Ратушасы бар.



# Ратуша

Монда шәһәр башлыгы олы кунаклар һәм Казан халкы белән очрашулар үткәрә. Ратушада Казан шәһәре Думасы утырышы уза.



# Сарай каршындагы мәйдан

Ул Казан үзәгендәге гаҗәеп матур урында урнашкан. Мәйдан Казан Кремле диварлары һәм Кремль яр буе, Федосеев урамы һәм Игенчеләр сарае белән уратып алынган.



# Сарай каршындагы мәйдан

Мәйданга декоратив плитә җәелгән, һәркайда чәчәкләр утыртылган, ясалма сулык та бар.




# Фёдор Шаляпин һәйкәле

Казань – город, где родился и вырос великий русский певец. И казанцы гордятся своим всемирно известным земляком.

Памятник обладателю уникального оперного баса был открыт в 1999 году на пешеходной улице Баумана, около Богоявленского собора. Место это было выбрано неслучайно: в этом храме он был крещён.

Казан – бөек рус җырчысының туып-үскән шәһәре. Казанлылар бөтен дөньяга атаклы якташлары белән горурланалар.

Уникаль бас тавышына ия җырчы һәйкәле 1999 елда җәяүлеләр йөри торган Бауман урамында, Богоявленский соборы янында ачыла. Әлеге урынның сайлануы очраклы түгел: бу чиркәүдә аны чукындырганнар.



# Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры

Столица Татарстана славится своими театрами. Крупнейший из них – Татарский академический государственный театр оперы и балета имени Мусы Джалиля.


Каждый год на сцене театра проходят два всемирно известных международных фестиваля: оперный – имени Фёдора Шаляпина и классического балета – имени Рудольфа Нуриева.

Казан үзенең театрлары белән данлыклы. Шуларның иң зурысы – Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры.

Ел саен театр сәхнәсендә ике зур халыкара сәнгать бәйрәме – Фёдор Шаляпин исемендәге опера фестивале һәм Рудольф Нуриев исемендәге классик балет фестивальләре үткәрелә.

Фасад и интерьер театра сочетают в себе классические формы и татарские национальные орнаменты.

Театрның фасады һәм интерьеры классик формаларны һәм татар милли орнаментларын берләштерә.



# Казан яшь тамашачылар театры

Исеменнән күренгәнчә, әлеге театрда балалар һәм үсмерләр өчен спектакльләр куела. Театрның туган көне дип 1932 елның 30 ноябре исәпләнә. Бу көнне беренче мәртәбә «Яшьтәш» спектакле сәхнәләштерелә.

Казан ЯТТ – күпсанлы театр фестивальләре катнашучысы. Театр һәм анда эшләүче артистлар хезмәте күп тапкырлар диплом һәм премияләргә лаек булды.




# Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры

Театр күренекле татар язучысы, актёры һәм драматургы исемен йөртә һәм үзенең тамашачыларын репертуарының төрлелеге белән һәрвакыт куандырып тора.

Тинчурин театры сәхнәсендә кызыклы комедияләр дә, гыйбрәтле драмалар да, гаҗәеп матур музыкаль әсәрләр дә куела.



# Зилант – Казанны саклаучы



# Зилант – Казанны саклаучы

Зилант – Казанның төп символы һәм саклаучысы. Риваять буенча, ул Кабан күле төбендә хан хәзинәсен саклый. Рәхмәтле казанлылар канатлы аждаһаны шәһәр гербында да гәүдәләндергәннәр.




# Александр пассажы





# Александр пассажы

Бу гаҗәеп матур бинаны сәүдәгәр Александр Александров төзетә. Бу галерея, үзенең гүзәл архитектурасыннан тыш, шәһәр кешеләрен төрле яңалыклар белән дә гаҗәпләндерә торган була. Әйтик, бу бинада моңа кадәр бөтенләй күрелмәгән «шәмсез яктылык» (электр уты), пыяла түбә, лифт һәм һава җылыткычлары булган.




# Казан дәүләт циркы





*Казанский государственный цирк*



# Казан дәүләт циркы

Казан циркына – 100 яшьтән артык. Цирк оригиналь бинасы белән бөтен дөньяга билгеле. Ул бер-берсенә тоташтырып куелган ике тәлинкәне хәтерләтә. Циркның яңа бинасы шәһәрдә 1967 елда барлыкка килә. Бу оригиналь корылманы шундук XXI гасыр бинасы дип атый башлыйлар.




# Миллениум күпере

Миллениум күпере – Казанның иң биек күпере. Ул Казансу елгасы ярларын тоташтыра. Күпер терәкләрендәге «М» хәрефе шәһәрнең 1000 еллыгын мәңгеләштерә һәм аның тагын бер истә кала торган символы булып тора.



# Миллениум күпере



# Татарстанның Милли музее



Казан – музейлар шәһәре. Безнең шәһәрдә аларның саны 50дән артык.

Татарстанның Милли музее 1895 елда ачыла. Музей бинасы шәһәрнең иң матур үзәк урамнарының берсе – Кремль урамында урнашкан.




# Татарстанның Милли музее

Ул – Россиянең иң борынгы музейларының берсе. Аның коллекциясендә тарих, археология, этнография һәм сәнгатькә караган 800 меңнән артык экспонат саклана.



*Булгарские украшения*



# Габдулла Тукай музее

Шамил йорты – 19 гасыр азагы Иске Татар бистәсендәге иң гүзәл архитектура һәйкәлләренең берсе. Әлеге бинада татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның Әдәби музее урнашкан.



«Шүрәле» һәм «Су Анасы» поэмалары – шагыйрьнең иң танылган әсәрләре. Музейда син Г.Тукайның шәхси әйберләрен, фотосүрәтләрен, кулъязмаларын һәм вафат булганнан соң ясалган битлеген дә (маскасын) күрә аласың.



# Меңьеллык музее

www.минемказан.рф

«Казан» Милли-мәдәни үзәге Казансу елгасының искиткеч гүзәл яры буенда урнашкан. Шәһәр юбилее уңаеннан анда Казанның Меңьеллык музее ачылды. Музей экспозиц ияләре шәһәрнең борынгы тарихы турында сөйли. Анда атаклы Казан таҗын да күрергә мөмкин. Кайчандыр аны Казан ханы Ядегәр Мәхмүт кигән булган. Музейга килүчеләрнең игътибарын шулай ук Казан ханнарының тәхете, шәһәр капкалары һәм ачкычы җәлеп итә.



*Казанская шапка*



# Сынлы сәнгать музее


Карл Маркс урамында урнашкан Татарстанның сынлы сәнгать музее 1967 елда ачыла.

Бу матур бинада элек Казан губернаторы резиденциясе булган. Хәзер биредә 16 гасырдан алып бүгенге көнгә кадәрге дәверләргә караган экспонатлар һәм рәсем сәнгате әсәрләре белән танышырга мөмкин.



# Татарстан Милли китапханәсе

www.минемказан.рф




# Татарстан Милли китапханәсе

Республиканың төп китапханәсе күренекле борынгы биналарның берсендә урнашкан. Бу йортны сәнәгатьче Ушков (бүген «бизнесмен» диярләр иде) үз кәләшенә туй бүләге итеп биргән.

Бинаның күркәм бизәлешендә уеп ясалган аждаһаларны, гаҗәеп бизәкләрне, витраж һәм алтынлау үрнәкләрен күрергә була.




# Казань




Станции метро Казани

1 Казан Кремле
2 Благовещение соборы
3 Сөембикә манарасы
4 Кол Шәриф мәчете
5 Ратуша
6 Фёдор Шаляпин һәйкәле
7 Миллениум күпере
8 Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры
9 Казанны саклаучы Зилант
10 Татарстанның Милли музее
11 Меңьеллык музее
12 Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры
13 Дәүләт сынлы сәнгать музее
Национальная библиотека Татарстана –
14 Татарстан Милли китапханәсе




15 «Казан Арена»
16 Спортның су төрләре сарае
17 Казан ипподромы
18 «Казан» гаилә үзәге
19 Казан дәүләт циркы
20 Казан парклары
21 Казан сулыклары
22 Казан мәчесе
23 Кремль яр буе
24 Казан университеты
25 Курчак театры
26 Казан яшь тамашачылар театры
27 Губернатор сарае
28 Сарай каршындагы мәйдан
29 Александр пассажы
30 Кекин йорты
31 Екатерина II каретасы
32 Габдулла Тукай музее

Казан – Россиянең спорт башкаласы. Безнең шәһәрдә даими рәвештә зур күләмле спорт ярышлары үтә.


# «Казан Арена»



# Казан Арена

Чистай урамында урнашкан әлеге стадион – Россиянең иң эре спорт мәйданчыгы. Ул 45 меңнән артык кешене сыйдыра. Стадион 2013 елда Бөтендөнья җәйге универсиадасы (Студентлар арасында халыкара спорт ярышлары) уздырылу уңаеннан ачылды. Анда әлеге гаять зур спорт бәйрәменең ачылу һәм ябылу тантаналары узды.

«Казан Арена» кырында 2018 елда футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары узачак.



# Спортның су төрләре сарае

Сибгат Хәким урамындагы әлеге спорт сарае шулай ук Универсиада-2013 уңаеннан төзелә. Ә 2015 елда ул спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатын кабул итте.



# Спортның су төрләре сарае

Чемпионатның талисманнары – Итил һәм Алсу исемле ак барслар. Спорт бәйрәме илчеләре исә – күренекле спортчылар һәм мәдәният эшлеклеләре.






www.минемказан.рф

# Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты-2015


FINA WORLD CHAMPIONSHIPS
KAZAN
RUSSIA 2015



# Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты-2015

2015 елда Казанда үткән спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты – исәп буенча 16 нчы чемпионат.

Ярышлар су спортының 6 төре – йөзү, ачык суда йөзү, суга сикерү, хай-дайвинг (экстремаль биеклектән суга сикерү), су тубы һәм синхрон йөзү буенча үткәрелде. Яңа дисциплина – хай-дайвинг рәсми рәвештә дөнья чемпионаты программасына күптән түгел генә кертелде.



# Казан ипподромы

«Казан» Халыкара ат спорты комплексы шәһәребезнең 1000 еллыгына ачыла. Әлеге үтә заманча комплекс Европада иң зурлардан санала. Ипподромның мәйданы 90 гектарга якын. Биредә халыкара ярышлар, шулай ук татарстанлыларның яраткан бәйрәме – Сабантуй көнендә ат чабышлары уздырыла.




# Казан ипподромы




# Казан парклары

Җиңү паркы Казанның  Яңа Савин районы үзәгендә ачылган. Монда хәрби техника музее һәм биеклеге 42 метрлы Җиңү стеласы урнашкан. Бөек Ватан сугышы геройлары истәлегенә куелган мемориал янында Мәңгелек ут яна.

Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 70 еллыгына «Хәтер Китабы» мемориалы ачылды.





# Казан парклары

Меңьеллык паркы Казанның меңьеллык тарихы символы буларак барлыкка килә. Парк тарихи символларга бай.

Паркка килүчеләрне бронза зилантлар каршы ала, ә үзәктә казанны хәтерләткән фонтан – зур бронза касә урнаштырылган. Ул татар халкының муллык һәм кунакчыллык символы булып тора.





# Казан парклары


Горький исемендәге үзәк ял паркы – Казанның үзәгендә урнашкан табигать тыюлыгы ул. Монда каеннарның сирәк төрләре үсә, тиеннәр яши.

Җырлый торган фонтаннар, чәчәкләр аллеясы, эскәмияләр куелган скверлар паркны шәһәрлеләрнең яраткан урыны итте.




Поющие фонтаны

# «Казан» гаилә үзәге



# «Казан» гаилә үзәге

«Казан» гаилә үзәгендә яшь гаиләләр теркәлә. Моның өчен берничә тантана залы бар. Берсе бөек Идел буе Болгар дәүләте дәверен чагылдыра, икенчесе – Казан ханлыгы чорын. Биредә күзәтү мәйданчыгы да бар. Аннан кунаклар хозурына шәһәрнең гүзәл манзарасы ачыла.



# Казан сулыклары

Кабан күле – Татарстанның иң зур күле. Серле күл турында күп риваятьләр сакланган. Шуларның берсе буенча, аның төбендә хәзинә – Казан ханының казнасы яшерелгән.



Болак – шәһәр үзәгендә урнашкан су каналы. Ул Түбән Кабан күлен Казансу елгасы белән тоташтыра, Уң Болак һәм Сул Болак урамнарын аерып тора. Болак аркылы 6 күпер салынган, аларның һәрберсенә тарихи исемнәре кайтарылган: Ложкин, Лебедев, Романов, Дегтярёв, Батурин һәм Болак.



# Казан мәчесе

www.минемказан.рф

Казан мәчесе – барлык Казан мәчеләренең җыелма образы. Патшабикә Елизавета Петровна фәрманы белән Казаннан Санкт-Петербургка, тычкан тоту өчен, утыз иң яхшы ата мәче җибәрелә.




Ул вакытта Петербургтагы Кышкы сарай тычканнар «һөҗүменнән» азапланган. Казан мәчеләре тычканнарны юк итеп кенә калмаган, ә яңа төр Петербург мәчеләре токымын барлыкка китергән.




Бауман урамы – Казанның иң иске урамнарының берсе. Ул – шәһәрнең тарихи үзәге аша үтә торган җәяүлеләр урамы.

# Екатерина II каретасы




Бик күптән 1767 елда императрица Екатерина II Идел буйлап сәяхәт итә. Казан патшабикәне хуш күңел белән каршы ала. Әлеге истәлекле визиттан соң күп тә үтми шәһәрдә яңа фабрикалар һәм заводлар, мәктәпләр, мәчет һәм чиркәүләр барлыкка килә, соңрак театр, гимназия һәм университет ачыла.

Екатерина II утырып йөргән каретаның оригиналын Татарстанның милли музеенда күрергә мөмкин. Ә Бауман урамында, шәһәрлеләрне һәм килгән кунакларны шатландырып, әлеге каретаның чуеннан коелган күчермәсе пәйда булды.

# Екатерина II каретасы





# Кремль яр буе

Кремль яр буе – казанлыларның гына түгел, шәһәр кунакларының да яраткан ял итү урыны. Казансу елгасы яр буе Кремль диварларыннан «Казан» милли мәдәни үзәгенә кадәр сузылган. Аннан ерак түгел Игенчеләр сарае, Сарай каршындагы мәйдан, ял итү өчен уңайлы скверлар һәм кафелар урнашкан. Казансу елгасы яр буеннан шәһәребезнең гаҗәеп матур манзарасы ачыла.




КАЗАНСКИЙ (ПР

# Казан университеты

Казан университеты Россия империясе тарихында өченче югары уку йорты булып тора. Ул 1804 елда император Александр I указы белән ачыла. Беренче ректоры бөек математик Николай Лобачевский була. Ул үзенең дөньякүләм ачышларын әлеге уку йортында башкара. Төрле елларда университетта Лев Толстой һәм Сергей Аксаков, Александр Бутлеров һәм Владимир Ульянов-Ленин кебек танылган шәхесләр укыган.



# Кекин йорты

Бина узган гасыр башында сәүдәгәр Леонтий Кекин заказы буенча салынган. Оригиналь проектның авторы – талантлы архитектор Генрих Руш. Табыш йорты (фатирлар вакытлыча яшәү өчен бирелгән) ике ай эчендә төзелгән. Моның белән Кекин ниндидер бәхәстә откан, диләр.

Бу бинада шулай ук шәхси гимназия, училище, театр, типография, китапханә һәм кибетләр урнашкан була. Сүз уңаеннан, нәкъ менә Кекин йортында шәһәрдә беренче электр күтәргеч барлыкка килгән. Без аны хәзер лифт дип атыйбыз.





# Курчак театры





# Курчак театры

Петербург урамында урнашкан «Әкият» курчак театры бинасы чып-чын әкият сараен хәтерләтә. Тылсымлы манаралар, балконнар, гаҗәеп бизәкле тәрәзәләр.

Ә эчендә – Шүрәле, Су Анасы, Щелкунчик һәм башка әкият геройлары патшалыгы. Алар курчак театры сәхнәсендә җанланалар һәм балаларга шатлык өләшәләр. «Әкият» театры репертуарында 30дан артык спектакль исәпләнә.



*Театр кукол*

www.tdpress.ru

www.минемказан.рф

**Киләсе очрашуларга кадәр!**



ISBN 978-5-906508-23-2